КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 27 ноябрь г.Казань № 1064

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турында» 1997 ел, 27 февраль, 175 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турында» 1997 ел, 27 июль, 175 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 11 март, 149 нчы, 2015 ел, 16 февраль, 95 нче, 2019 ел, 8 февраль, 83 нче, 2020 ел, 30 декабрь, 1254 нче, 2022 ел, 29 сентябрь, 1048 нче, 2023 ел, 15 февраль, 149 нчы, 2023 ел, 29 март, 373 нче, 2023 ел, 16 июнь, 723 нче, 2024 ел, 12 сентябрь, 772 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турында нигезләмәнең 14 пунктында «атасы исеме» сүзеннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты составында:

Комитет составыннан Р.А.Ратникованы чыгарырга;

Раушан Булат улы Зариповның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы»;

Бикчәнтәев Фәрид Рәфкать улы вазыйфасының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Театр эшлеклеләре берлеге - Татарстан Республикасы Театр эшлеклеләре берлеге бүлекчәсе рәисе, «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе баш режиссеры (килешү буенча)»;

Александр Андреевич Карповның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасы генераль директоры урынбасары (килешү буенча)»;

Максимова Ольга Александровна вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Социаль-фәлсәфә фәннәре һәм массакүләм коммуникацияләр институтына караган гомуми һәм этник социология кафедрасы доценты (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин